Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 30 ноябрендә,9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Новотроицк авылында Набережная урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 30 ноябрендә, 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Новотроицк авылындагы Завод, Болын, Нагорный, Кыр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2019 елның 30 ноябрендә, 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Новотроицк авылындагы Совет, Беренче Май, Үзәк урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Новотроицк авыл җирлегенең Новотроицк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункттагы юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыены этапларын Новотроицк авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Новотроицк авылы, Совет урамы, 8 нче йорт.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегенең Новотроицк авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Новотроицк авыл башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны җыен үткәрү кененә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Новотроицк авылы, Совет урамы, 10 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Новотроицк
авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Лотфуллин